ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422700 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОСЕЛЬСОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

Тел./факс: +7(84365) 2-35-82, 2-35-85, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**16 май 2023 ел** **№ 9**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмөшле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы «Житештерү һәм куллану калдыклары турында», 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында», 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы «Энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», 2020 елның 28 декабрьдәге 2314 нче номерлы «Яктырткычлар, электр лампалары өлешендә, дөрес булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин була торган, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмөшле лампалар туплану урыннарын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 йорт

2. Күпфатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмөшле лампалар кулланучыларда эшкәртелгән терекөмөшле лампаларның туплану урыннары «Яктырткычлар, электр лампалары өлешендә, дөрес булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин була торган, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әгәр күпфатирлы йортларда терекөмөшле лампаларның туплану урыннарын оештыру биналар булмау сәбәпле мөмкин булмаса, шул исәптән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларда милекчеләр, яллаучылар, бина кулланучылары очен дә билгеләнгән.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә терекөмөшле лампалар тупланган урынның урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (стойкаларда) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе                                                  Р.Ф. Нуруллин